**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# К А Р А Р

№ 9 Кәрәкәшле авылы 20 октябрь 2020 ел

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 15 маддәсендәге 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен расларга.

2. Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2020 елның 3 сентябрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында”гы 14 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, http://jutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча муниципаль районның рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев

Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2020 елның 20 октябрендәге 9 санлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба – авыл җирлеге) һәм Татарстан Республикасы «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба – Район) арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен тапшыру турында килешүләр төзүнең әлеге тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба - «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон) нигезендә эшләнде.
2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешү төзү буенча җирлек һәм район вәкаләтләре (алга таба – килешү):
2.1. Җирлек Советы:
1) килешү төзү тәртибен раслый, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;
2) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү (тапшыру) турында карар кабул итә;
3) кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота;
4) әгәр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү (тапшыру) турында килешүдә башкасы каралмаган булса, район тарафыннан кабул ителгән (тапшырылган) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар кабул итә;
5) төзелгән килешүләрнең үтәлешен контрольдә тота.
2.2. Район:
1) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыруны (кабул итүне) башлап җибәрә;
2) җирлек советының кабул ителгән карары нигезендә килешү проектын эшләүне гамәлгә ашыра һәм аңа кул куюны тәэмин итә;

3) тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен билгеләү тәртибен билгели;
4) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны исәпләүне башкара;
5) килешү төзи һәм аны рәсми бастырып чыгаруга (халыкка җиткерүгә) җибәрә;
4) әгәр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү (тапшыру) турында килешүдә башкасы каралмаган булса, район тарафыннан кабул ителгән (тапшырылган) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар кабул итә;
7) төзелгән килешүләрнең үтәлешен тәэмин итә.
2.3. Җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләре район җирле үзидарә органнарына күчкән хокукый актлары Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган өлешендә, районның җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгәнчегә һәм тиешле хокукый мөнәсәбәтләрне җайга сала торган муниципаль хокукый актлар үз көченә кергәнче гамәлдә була.
Тиешле хокукый мөнәсәбәтләрне җайга сала торган район җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары үз көченә кергән көннән алып, җирлек җирле үзидарә органнарының моңа кадәр кабул ителгән хокукый актлары кулланылмый.
3. Җирлекнең җирле үзидарә органнары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен җирлек бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә тапшыру турында район җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзергә хокуклы.
Шул ук вакытта районның җирле үзидарә органнары «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, җирле үзидарә органнарына җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә җирлек территориясендә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.
4. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен җирлек һәм районның җирле үзидарә органнары тапшыра ала.
5. Авыл җирлеге башкарма комитеты үз инициативасы белән яисә районның җирле үзидарә органнары инициативасын карап, 30 көн эчендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында җирлек Советының карары проектын әзерли.
6. Авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләрнең бер өлешен җирлек Советына норматив хокукый актлар керткәндә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тапшыру турында җирлек Советы карары проектын кертә.
7. Җирлек советы җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен район җирле үзидарә органнарына тапшыру турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны район җирле үзидарә органнарына карауга җибәрә.
8. Җирлек советы карарын карауның уңай нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы тарафыннан җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм районның җирле үзидарә органнары арасында килешү төзелә.

8.1. Килешүне әзерләгәндә, караганда һәм төзегәндә түбәндәге килешү шартлары билгеләнә:
1) килешүнең исеме, аны төзү көне һәм урыны;
2) әлеге җирле үзидарә органнары исеменнән эш итүче муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары исеме, алар арасында килешү төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары исеме, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының фамилиясе, исеме, атасының исеме, килешү төзегәндә аталган затлар гамәлдә булган норматив хокукый актларның исеме;
3) килешү предметы (килешүнең төп юнәлеше, аның төп эчтәлеген нәрсә тәшкил итүе күрсәтелә);
4) тапшырыла торган вәкаләтләрнең составы (исемлеге) (вәкаләтләрнең эчтәлеге федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына туры килергә тиеш);
5) тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен үз матди һәм финанс ресурсларыннан файдалану, үтәлешен тикшереп тору һ. б.) һәм бурычлары (муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына тапшырылган вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашырганда финанслауга субвенцияләр бүлеп бирү, бирелгән вәкаләтләрнең билгеле бер таләпләрдән дә ким булмаган дәрәҗәдә үтәлү нәтиҗәләре һ. б.) хокуклары (үз матди һәм финанс ресурсларыннан файдалану, аларның үтәлешен тикшереп тору һ. б.);
6) җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү (тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле еллык бюджетара трансфертлар күләме, аларны җирле бюджетка күчерү, җирле бюджет структурасында исәпкә алу һәм җирле үзидарәнең тиешле органы исәбенә күчерү тәртибе);
7) тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен кирәкле мөлкәтне тапшыру шартлары;
8) тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди чаралар исемлеген билгеләү тәртибе яисә исемлеге;
9) тапшырыла торган вәкаләтләрне үтәү турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе (хисаплылык төрләре, формалары, рәвешләре һәм вакытлары күрсәтелә);
10) яклар тарафыннан килешү шартларын гамәлгә ашыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе (контроль тәртибе һәм рәвешләре күрсәтелә);
11) килешү шартларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы (килешүне үтәмәгән өчен җаваплылык төрләре һәм финанс санкцияләре күрсәтелә);
12) килешүне гамәлгә ашыру барышында яклар тарафыннан бәхәсләрне карау тәртибе;
13) килешү төзелә торган вакыт һәм аның үз көченә керү көне (рәсми басылып чыккан көненнән (халыкка җиткерелгән көннән дә иртәрәк түгел);
14) килешүне үзгәртү һәм өзү, шул исәптән килешүне вакытыннан алда туктату яисә аның аерым нигезләмәләрен, шулай ук килешүне үзгәртү һәм өзү нәтиҗәләре һәм тәртибе;
15) йомгаклау нигезләмәләре (килешү һәм башка килешүләр ничә нөсхәдә төзелгән?);

16) районның җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгаруга (халыкка җиткерергә) йөкләмә;
17) муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының урнашу урыны (килешүче якларның юридик адреслары күрсәтелә);
18) килешүче якларның имзалары.
5.2. Килешүнең мөһим шартлары булып түбәндәгеләр тора:
1) килешү төзелә торган вакыт;
2) гамәлдә булуын, шул исәптән вакытыннан алда туктатуны, нигезләрне һәм тәртибен билгели торган нигезләмәләр;
3) тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларның еллык күләме;
4) килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләре.
Килешү проектын эшләү өчен һәр яктан тигез санда вәкилләрне кертеп, эшче төркем төзелергә мөмкин. Эшче төркем үз эше нәтиҗәләре буенча һәм якларның мәнфәгатьләрен максималь рәвештә исәпкә алучы килешү проектын әзерли.
9. Әгәр җирлек Советы җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны район җирле үзидарә органнарына тапшыру турындагы карар проектын кире какса, 30 көн эчендә алар инициативасын карап тикшерү нәтиҗәләре турында хат җибәрелә.
10. Килешүдә каралган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле финанс чаралары җирлек бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә район бюджетына бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.
Бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган очракта алар җирлек бюджетына ун көнлек вакыт аралыгы белән кире кайтарылырга тиеш.
Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында бюджет законнары нигезендә район һәм җирлек бюджеты турындагы карарларга үзгәрешләр кертелә, анда тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар карала.
Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек бюджетыннан район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.
Җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан районның җирле үзидарә органнарына бирелгән вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары килешүдә беркетелгән вакытларда һәм шартларда күчерелә.
11. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәк булган очракта, түләүсез ашыгыч файдалану килешүе нигезендә муниципаль милек тапшырыла.
Түләүсез файдалану килешүе тиз арада төзелә һәм килешү гамәлдә булу вакыты күрсәтелә.
12. Килешү нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен районның җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга хокуклы.
13. Вәкаләтләрен тапшырган җирле үзидарә органнары тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерәләр, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүматны соратып алалар.
14. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:
- ике якның килешүе буенча;

- берьяклы тәртиптә, бер як үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта.

15. Килешүнең гамәлдә булу вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырган район җирле үзидарә органы 14 көн дәвамында файдаланылмаган финанс чараларын, матди ресурсларны һәм җирлекнең җирле үзидарә органына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган мөлкәтне кире кайтара.

16. Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр, сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр яки килештерү процедураларын үткәрү юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.